# КӨЛЛИЯТ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ТУРЫНДА БИОГРАФИК БЕЛЕШМӘ

- **Рәхмәтуллин Хәлил Фәхри улы**
  **(1930-1932 нче еллар)**

  Агропедтехникумның язмышы ышанычлы кулларга эләгә. Беренче укытучылар – сәләтле, иҗади, үз эшенә тугъры, тормыш һәм укыту тәҗрибәсенә ия булган, җаваплы һәм зыялы кешеләр була. 1932 нче елда агропедтехникум элеккеге 4 сыйныфлы шәһәр приход училищесында нигезләнә. Бу училище революциягә кадәр бөтен дөньяга танылган җырчы Ф.И. Шаляпинның укуы белән данлыклы.

- **Гайсин Ләбиб Хөсәен улы**
  **(1932 -1938 нче еллар)**

  Республикада танылган педагог һәм оештыручы. 1935 нче ел Арча педагогика техникумы өчен истәлекле ел була. РСФСР ның Мәгариф халык комиссары А.С. Бубнов техникумга килә һәм матди һәм укыту-методик яктан тәэмин итү өчен күп эш башкара. Техникум китапханәсенә 80 мең сәнгать әдәбияты дәреслеге сатып алына. Ашханә, тулай торак төзелә башлый. 1937 нче елда уку йортының исеме үзгәрә – Арча педагогия училищесы исемен ала.

30 нчы елларда училище җитәкчелеге еш үзгәреп тора. Л.Х. Гайсиннан соң директор вазифасын башкаручылар:

- **Яфаев Г.С.**
  (1938 нче ел)
- **Розаков М.Г.**
  **(**1938-1940 нчы еллар)

**Авыр сугыш елларында училищены җитәкләгән директорлар:**

- Гафаров Ш.Г. –1940-1941 еллар
- Фарукшин – 1941 ел
- Апазов – 1942 ел
- Мансуров – 1942 ел
- Московкин А.Ф. – 1942-1943 еллар
- Багаутдинов – 1943 ел
- Абдуллин – 1943 ел
- Гайсин Л.Г. – 1943-1944 еллар
- Искәндәров Х.Ф. – 1944-1946 еллар
- Гафаров Ш.Г. – 1946-1947 еллар
- Табаров З.Н. – 1947-1950 еллар

- **Тупеев А.Х.**
  (1950- 1957 нче еллар)

Республикада танылган халык мәгарифен оештыручы һәм халык мәгарифе учреждениеләре җитәкчесе.

Бу елларда укытучылар әзерләү системасының төп компоненты булып педагогик практика тора. Педучилищеның үз башлангыч мәктәбе барлыкка килә, мәктәп шартларында укыту-методик лаборатория булдырыла.

- **Насыров Гата Сираҗетдин улы**
  (1957-1960 нчы еллар)

Тәҗрибәле педагог һәм җитәкче. Үзенә, укытучыларга һәм укучыларга таләпчән.

1958-1961 нче елларда педагогия училищесының бинасы төзекләндерелә һәм реконструкцияләнә. Төп бинага кирпечтән эшләнгән ике этажлы яңа укыту корпусы корыла. Шулай ук яңа спорт залы, берничә сыйныф бүлмәсе салына. Китапханә фонды рус һәм чит илләр әдәбиятының классик әсәрләре белән тулыландырыла.

- **Блинов Гафур Әбүбәкир улы**
  (1960-1963 нчы еллар)

Укыту-тәрбия процессы камилләштерелә һәм материаль техник база ныгытыла.

Илдә хәлнең яхшыруы нәтиҗәсендә яңа мәктәпләр ачыла, Арча педучилищесында башлангыч сыйныф укытучылары әзерләү буенча тугыз айлык курслар ачыла. Яңа укыту планнары, методик ярдәмлекләр төзелә. Башлангыч сыйныф укытучыларын чыгару арта.

Гафур Әбүбәкир улы – педагогика фәннәре кандидаты, 1972-1992 нче еллар. В.Г. Короленко исемендәге Глазов пединститутында 1972-1992 нче елларда эшли.

1981-1989 елларда читтән торып уку бүлегенең проректоры. Н.К. Крупская медале, «Халык мәгарифе отличнигы» билгесе белән бүләкләнә.

1973-1981 елларда педагогика һәм башлангыч укыту методикасы кафедрасы мөдире.

- **Ибраһимов Мөнәвир Гәрәй улы**
  (1963 – 1981 нче еллар)

1963 нче елдан башлап 18 ел дәвамында Мөнәвир Гәрәй улы Арча педагогия училищесын җитәкли.

Ул хезмәт эшчәнлеген гади укытучыдан башлый, Бөек Ватан сугышын үтә, КПСС РК сәркатип булып эшли. Эшлекле һәм таләпчән булу белән беррәттән, укучылар һәм укытучылар арасында авторитетны тиз яулый.

Нәкъ менә шушы елларда М.Г. Ибраһимов җитәкчелегендә педагогик коллективның иҗади формалашуы башлана. Бу чорда училищеның стабильлеккә күчүе, нәтиҗәлелек сыйфатының үсүе күзәтелә. Чыгарылыш студентлары уку йортына укытучы булып кайта башлый. 70 нче еллар ахырында училищеның ныклы материаль-техник базасы барлыкка килә. Бу дәресләрне һәм дәрестән тыш эшчәнлекгне югары дәрәҗәдә үткәрергә мөмкинлек бирә.

М.Г. Ибраһимовның җитәкчелеге астында, педагогик коллективның иҗади эзләнү һәм камилләшү стиле республика һәм аның чикләрендә дә таныла.

- **Сәгъдеев Илдус Абдрахман улы**
  (1981-2002 нче еллар)

Сәгъдеев Илдус Абдрахман улы – РФ мәгариф отличнигы. ТР ның atказанган укытучысы. Арча районының Мактаулы гражданины, «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.

80-90 нчы елларда педучилищеның матди-техник базасы яңартылды һәм ныгыды: яңа өч катлы уку бинасы, 370 урынга исәпләнгән өч катлы студентлар өчен тулай торак, укытучылар өчен коттедж тибындагы 18 фатир, чаңгы базасы, яңа спорт залы, теплица төзелде.

1985 нче елда педучилище яңа бинага күчә, 1992 елда колледж статусы ала һәм КДПУ һәм ТДГГИ ның укыту-методик структур бүлекчәсенә әверелә.

1992 нче ел – педучилищены Арча педагогия көллиятенә үзгәртеп кору елы. 2000 нче ел Арча педагогия көллиятенең 70 еллыгы һәм «Әлифба» музее ачылу белән бәйле.

Коллектив Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиевнең Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

- **Гарипов Шәфигулла Зәйнулла улы**
  (2002-2005 нче еллар)

Аның җитәкчелеге астында Арча педагогия көллияте фәнни эксперимент һәм инновацион үсеш режимында уңышлы гына эшли. Үз эшенә җаваплы каравы, үз-үзенә һәм башка укытучыларга карата таләпчәнлеге, гаделлеге һәм армас-талмас иҗади эзләнүчәнлеге аны тагын бер кат чын җитәкче буларак бәяли. Кыска гына вакыт эчендә көллиятнең матди-техник һәм укыту-методик ягын ныгыту буенча Шәфигулла Зәйнулла улы тарафыннан бик зур хезмәт куелган: икенче компьютер классын, чит тел кабинетларын җиһазландыру, шулай ук кирәкле техник чаралар булдыру.

- **Габдрахманов Наил Газиз улы**
  (2005-2012 нче еллар)

ТР атказанган укытучысы, халык мәгарифе отличнигы, "Мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе һәм «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медаль белән бүләкләнә.

Ул җитәкчелек иткән чорда Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте милли мәгарифне үстерүдәге казанышлары өчен К. Насыйри исемендәге премия лауреаты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы грантлары икенче Республика конкурсында җиңүләр яулады.

- **Сафина Эльмира Назих кызы**
  (2012-2013 нче еллар)

РФ нең гомуми белем бирүнең мактаулы хезмәткәре, 2012 нче елдан алып 2013 нче елга кадәр педагогия көллияте директоры булып эшли. Аның эшләү дәверендә бинаны капиталь ремонтлау, барлык уку кабинетларын яңадан рәсмиләштерү һәм җиһазлау эшләре башланды. Кадрлар белән эшләүгә зур игътибар бирелде.

- **Гарипова Гөлнара Фидаил кызы**
  (2013 нче елдан башлап)

Эрудицияле, югары квалификацияле педагог, оста җитәкче; аның эшчәнлегенең нигезе булып кешеләр белән аралаша белү, һәр кешедә шәхесне күрү, эшкәтугърылыклы, җаваплы булу тора.

Ул эшләгән елларда педагогик көллияткә һәм тулай торакка капиталь ремонт ясалу төгәлләнде, территория чәчәк бакчасына әверелде, уку йорты милли кадрлар әзерләү үзәгенә әйләнде, милли мәгарифне үстерү үзәге каршындагы гимназия сыйныфлары ачылды, мәктәпкәчә белем бирү өчен кадрлар әзерләү яңартылды.